СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

11.02.2020г. Алабуга шәһәре №444

«2020 елга Алабуга муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның алдан хәбәр итү планын (программасын) раслау турында»гы 2019 елның 30 декабрендәге 438нче санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178нче санлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү һәм аны тоту турында Алабуга муниципаль район Советының 2009 елның 22 декабрендәге 257нче санлы карары белән расланган нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль район Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Алабуга муниципаль район Советының 2019 елның 30 декабрендәге 438нче санлы карары нигезендә расланган 2020 елга Алабуга муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның алдан фаразланган планына (программасына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче бүлекнең 5нче пунктына өстәргә:

| № п/п | Атамасы | Урнашкан урыны | Мәйданы, кв.м. | Хосусыйлаштыру срогы |
|---|---|---|---|---|
| 26 | Торак булмаган бина һәм җир кишәрлеге | Алабуга шәһәре, Татарстанның 10 еллыгы урамы, 9 | 1041,0<br>554,0 | 1 квартал |
| 27 | Торак булмаган бина һәм җир кишәрлеге | Алабуга шәһәре, Кече Покров урамы, 40 | 148,4<br>989,0 | 2 квартал |

2. Әлеге карар «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178нче санлы Федераль закон нигезендә «Интернет» челтәрләрнең рәсми сайтында урнаштырылырга һәм рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарны үтәү өчен контрольне җир-милек мөнәсәбәтләре һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары З.Х.Сөнгатуллина